РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**6 февраль 2019 ел** **Чистай шәһәре** **№ 41/1**

Татарстан Республикасы Чистай
муниципаль районы Советының
24.03.2006 елгы “Чистай
муниципаль районы Советы
депутаты статусы хакында”гы
Нигезләмә турында”гы 7/5нче
карарына үзгәрешләр кертү турында

Чистай шәһәр прокуратурасының 25.12. 2018 елгы 02-08-02-2018нче протестын карап, 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131нче Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

*1.* Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының 24.03.2006 елгы “Чистай муниципаль районы Советы депутаты статусы хакында”гы Нигезләмә турында”гы 7/5нче карары белән расланган (Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының 09.09.2010елгы 42/5 нче, 31.03.2016 елгы 7/5 нче карарлары редакциясендә) Чистай муниципаль районы Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2нче маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2нче маддә. Депутат вәкаләтләре срогы

Район Советы депутаты вәкаләтләре шул рәвешле Чистай муниципаль районы составына керүче җирлек башлыгы вазифасына кергәннән көннән яки әлеге җирлек

Советы депутатының район Советы депутаты итеп сайланган көннән башлана һәм шул рәвешле җирлекнең яңадан сайланган башлыгы вазифасына кергән көннән яки әлеге җирлектән район Советы составына депутатны чираттагы сайлау турындагы карар үз көченә кергән көннән туктала.”;

1.2. 3нче маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“ 3нче маддә. Депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

Федераль законнар белән каралган очракта депутатның вәкаләтләре вакытыннан алда туктала.”;

1.3. 4нче маддәнең 2 нче пункты көчен югалткан дип танырга;

1.4. 7нче маддәне түбәндәге эчтәлектәге 5-7нче пунктлар белән тулыландырырга:

“5. Депутатның сайлаучылар белән очрашулары биналарда, махсус бүлеп бирелгән урыннарда, шулай ук аларны үткәрү тормыш эшчәнлеген, транспорт яки социаль инфраструктураны, элемтәне бозмаган, җәяүлеләрнең һәм (яки) транспорт чарасының хәрәкәтенә яисә гражданнарның торак биналарга яки транспорт яки социаль инфраструктура объектларына керүенә комачаулык тудырмаган шартларда ишек алды территорияләрендә үткәрелә. Шундый очрашулар турында Татарстан Республикасының башкарма власть органнарына яки җирле үзидарә органнарына хәбәр итү таләп ителми. Шуның белән бергә депутат күрсәтелгән органнарга аларны үткәрү көне һәм вакыты турында алдан хәбәр итәргә хаклы.

6. Районның җирле үзидарә органнары депутатлар сайлаучылар белән очрашу үткәрү өчен махсус бүлеп бирелгән урыннарны билгелиләр, шулай ук депутатлар сайлаучылар белән очрашу үткәрү өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган биналарның исемлеген һәм аларны бирү тәртибен билгелиләр.

7. Район Советы депутатының сайлаучылар белән ачык чаралар формасындагы очрашулары Россия Федерациясенең җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, йөрүләр һәм пикетлар турындагы законнары нигезендә уздырыла.”;

1.5. 13нче маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“13 нче маддә. Депутатның вазифаи затлар тарафыннан беренче чираттагы тәртиптә кабул ителүгә хокукы

Депутат үз эшчәнлеге мәсьәләләре буенча Чистай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының вазифаи затлары тарафыннан беренче чираттагы тәртиптә кабул ителү хокукыннан файдалана.”;

1.6. 14 нче маддәнең 2 һәм 3нче пунктлары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның үтәлүенә контрольлек итүне Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль<br>районы башлыгы Д.А. Иванов